| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ КАЕНСАРСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**КУКМОРСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ КАЕНСАР**<br>**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　К А Р А Р

Каенсар авылы

18 декабрь 2023 ел　　　　　　　　　　№35

Каенсар авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Каенсар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Каенсар авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 02 ноябрендәге 27 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 8 номерлы, 2020 елның 23 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 5 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 16номерлы, 2023 елның 27февралендәге 5 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 30 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Каенсар авыл җирлеге башлыгына класслы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль

районы Каенсар авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.Х.Исхаков